**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Пәнәче авыл җирлегенең Түбән Пәнәче торак пунктында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**16 ноябрь 2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 16 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең Түбән Пәнәче торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- зиратта югары үсә торган агачларны кисеп алу».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 32 кеше кертелгән, җыенында 17 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе буенча гражданнар җыенында катнашучыларның 15 кеше тавыш бирде;

“Каршы” дип 2 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең Түбән Пәнәче торак пунктында гражданнар җыены үткән, гражданнар җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең Түбән Пәнәче торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2023 елда үзара салымны 500 сумм күләмендә билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- зиратта югары үсә торган агачларны кисеп алу» - дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгы** ________________ **М. Х. Туктаров**